ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail:KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
№6 05.03. 2021 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән территориядә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән территориядә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга. (1 нче Кушымта).
2. Авария хәлендәге, коры-сары һәм куркыныч тудыручы яшел утыртмаларны кисү буенча комиссия (килешенеп) төзергә. (2 нче Кушымта).
3. Авария хәлендәге, коры-сары һәм куркыныч тудыручы яшел утыртмаларны кисү буенча комиссия турындагы Нигезләмәне төзергә. (2 нче Кушымта).
4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Н.Сәләхетдинов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге
Башкарма комитетының
05 март 2021 ел, № 6
карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән территориядә яшел утыртмаларны кисү тәртибе турындагы

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

яшел утыртмалар - табигый һәм ясалма агач, куаклыклар һәм үләнчел үсемлекләре (паркларны, скверларны, бакчаларны, газоннарны, чәчәклекләрне, шулай ук аерым торучы агачларны һәм куакларны да кертеп);

табигый территорияләр - бердәм географик (климатик) шартларда формалаштырылган җирлек рельефының, туфракларның, үсемлекләрнең билгеле бер төрләрен үз эченә алган, хуҗалык эшчәнлеге кагылмаган яисә аз кагылган территорияләр;

яшелләндерелгән территория, ясалма төзелгән яшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге җирләрнең аз төзелгән участоклары, алар чикләрендә өслекнең кимендә 50 процентын үсемлекләр капламы тзшкил иткән кишәрлекләр;

Урманлы территорияләр - табигый килеп чыккан урман үсемлекләре белән капланган төрле функциональ билгеләнештәге табигать территорияләре кишәрлекләре;

агач – диаметры 5 см дан да ким булмаган ачык беленеп торган кәүсәле, 1,3 м биеклектәге үсемлек,(үсентеләрдән тыш);

куаклык – күпъеллык, берничә кәүсәле (агачтан аермалы буларак) туфрак өслегендә тармакланып үсүче үсемлек;

үлән капламы - газон, табигый үлән үсемлеге;

Өрәмәлек – ниндидер бер урында куе булып үсүче үсемлекләр, куаклыклар;

яшел массив – территориясендә 50 нөсхәдән артык 15 еллык (һәм аннан артыграк) агачлар үсә торган территория участогы;

яшел утыртмаларның зарарлануы - аларның үсешен туктатуга китерми торган яшел утыртмаларга зыян китерү, шул исәптән ботакларның, тамыр системасының механик зарарлануы, кабыкның бөтенлеген, тере тамыр капламының бөтенлеген

бозу, яшел үсентеләрнең яисә тамыр зонасында туфракның зарарлы матдәләр белән пычрануы, ут төртү яисә башка төрдәге йогынты ясау;
яшел утыртмаларны юкка чыгару (юкка итү) - яшел утыртмаларны кисү яисә аларның үсешен туктатуга китергән башка төрле зарарлану;
компенсацион яшелләндерү - юкка чыгарылган яки зарарланган үсентеләрне ( 2 коэффициенты белән) яңадан торгызу.

## 2. Яшел утыртмаларны саклауның төп принциплары

Авыл җирлеге территориясендә үсә торган яшел үсентеләрне саклау, рекреацион, эстетик функцияләр башкара һәм сакланырга тиеш.
2.1.Авыл җирлеге территориясендә (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) урнашкан барлык яшел утыртмалар (агачлар, куаклар) сакланырга тиеш.
2.2.Авыл җирлеге территориясендә яшел утыртмаларның сакланышын һәм аларны үстерү өчен шартларны тәэмин итү бурычлары оешмаларга үзләре белдергән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән кишәрлекләрдә - шушы оешма җитәкчеләренә йөкләнә.
2.3.Яшел утыртмалар урнашкан җир кишәрлекләреннән файдаланучылар һәм арендаторлар яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итәргә, яшел утыртмаларны тиешенчә карауны тәэмин итәргә тиеш.
2.4.Авыл җирлеге территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.
2.5.Җир кишәрлеген сайлау акты, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документациясе яшел утыртмаларның торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләрдә һәм проектлана торган объектның яшел утыртмаларга йогынтысын тулысынча бәяләүдә булырга тиеш.
2.6.Яшел территорияләрдән һәм яшел массивлардан яшел утыртмаларның тереклек эшчәнлеген тәэмин итү белән бер үк вакытта файдалану рөхсәт ителми.

## 3. Яшел утыртмаларны (агачларны, куакларны) кисү тәртибе

3.1.Авыл җирлеге территориясендә яшел үтыртмаларны рөхсәтсез кисү тыела.
3.2.Авыл җирлеге территориясендә агач һәм куакларны кисү рөхсәт нигезендә башкарыла.
3.3.Рөхсәт бирү мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы булмаган очракта гамәлгә ашырыла.
3.4.Яшел утыртмаларны кисү эшләре гариза бирүченең акчасына башкарыла. Агачларны кисү бары тик аттестацияләнгән белгечләргә генә рөхсәт ителә.
3.5.Утыртмаларны егу, киселгән яшел утыртмаларны һәм киселгән калдыкларын төяү һәм алып китү эшләре эш башланган көннән алып өч көн эчендә гариза бирүче хисабына башкарыла. Киселгән яшел утыртмаларны һәм киселгән калдыкларны эш башкарылган урында саклау тыела.

3.6. Агач кисү урыны белән чиктәш территориядә газонга, яшел үсентеләргә зыян килгән очракта, эшләр башкаручы территория хуҗасы һәм контроль органнары белән аларның үз компетенциясе чикләрендә килешенгән вакытта, әмма зыян килгән вакыттан ярты елдан да соңга калмыйча, аларны мәҗбүри рәвештә яңадан торгыза.

3.7.Агачны кискән өчен түләмичә агач һәм куакларны кисү авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителергә мөмкин:

яшел үсентеләрне тәрбияләү, санитар кисүләр һәм реконструкцияләү;

авария хәлендәге һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау;

Дәүләт эпидемиология күзәтчелеге бәяләмәсе булса, торак һәм җәмәгать биналарында яктылыкны боза торган агачларны һәм куакларны кисү;

Авария хәлендәге (аварга мөмкин булган, корыган) агачларны һәм куакларны кисү.

Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел утыртмаларны кисүче мөрәҗәгать итүчегә авыл җирлеге башкарма комитеты белән килештерелгән урыннарда компенсацион яшелләндерү үткәрергә кирәк.

3.8.Авария хәлендәге, корыган һәм иминлеккә куркыныч тудыручы яшел утыртмалар Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы вәкиле катнашында авыл җирлеге башкарма комитетының 6 нчы карары нигезендә төзелгән комиссия тикшерүе нигезендә киселә.

3.9.Рөхсәтсез кисү яисә яшел утыртмаларны юкка чыгару дип танылa:

Рөхсәт кәгазендә күрсәтелмәгән кишәрлектә, рөхсәт ителгән күләмнән артыграк санда, рөхсәт ителмәгән агач токымнарын кисү;

ут төртү яки ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агачларны һәм куакларны юк итү яки зарарлау;

кәүсәләргә тимерчыбыктан боҗралар кигезү яки кәүсәне астан кисү;

үсә торган агачларның һәм куакларның үсеш туктатылганчыга кадәр зарарлау;

агач һәм куакларны ташландык сулар, химик матдәләр, калдыклар һәм башкалар белән зарарлау;

корыган агачларны үз белдегең белән кисү;

үсә торган агачларга һәм куакларга башка төрле зыян салу.

4. Компенсацион яшелләндерү

4.1.Компенсацион яшелләндерү яшел утыртмаларны рөхсәт белән кискән, аларга законсыз зыян салган яки юк иткән очракларда гамәлгә ашырыла. Компенсацион яшелләндерү агачлар, куаклар һәм газоннар утырту өчен яраклы сезонда башкарыла, әмма яшел утыртмаларны зарарлау яки юкка чыгару факты билгеләнгән вакыттан алып бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

4.2.Компенсацион яшелләндерү гражданнарның яисә юридик затларның мәнфәгатьләрендә яисә хокукка каршы гамәлләр нәтиҗәсендә яшел үсентеләрне зарарлау яки юкка чыгару булган очракта башкарыла.

4.3.Әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларга китерелгән зыян табигый формада - компенсация рәвешендә капланырга тиеш: юкка чыгарылган 2 коэффициенты белән юкка чыгарылган яшел үсентеләрне яңадан торгызу.

5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда яшел утыртмаларны саклау

5.1.Авыл җирлегендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру яшел утыртмаларны яклау таләпләрен үтәп алып барыла.

5.2.Яшелләндерелгән территорияләр, шул исәптән яшел массивлар, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре, аларның максатчан билгеләнешенә бәйле булмаган төзелеш һәм алардан файдалануга тапшырылырга тиеш түгел. 5.3.Яшел утыртмалар утыртылган җир кишәрлекләрендә төзелеш эшләрен оештырганда, проект алды документациясендә киселергә тиешле яшел утыртмаларга бәя булырга тиеш. Мондый очракларда зыянны каплау киселгән агач өчен һәм әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә компенсацион яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

6. Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда яшел утыртмаларны саклау

6.1.Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда сәүдә һәм башка эшкуарлык эшчәнлеген алып бару авыл җирлеге башкарма комитеты рөхсәтеннән башка гына эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела. 6.2.Эшмәкәрлек эшчәнлеген яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда гамәлгә ашырганда шартлау куркынычы булган, ут куркынычы булган һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел үсентеләрне зарарлауга яисә юкка чыгаруга китерергә сәләтле башка гамәлләр тыела.

7. Административ җаваплылык.

7.1.Әлеге Нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күлавыл жирлеге
Башкарма комитетының
05 март 2021 ел,№6
карарына
2нче кушымта

Авария хәлендәге,коры-сары һәм куркыныч тудыручы яшел утыртмаларны кисү буенча комиссия составы

1.Сәләхетдинов Илгизәр Нуретдинович — Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы.

2.Гатиятова Фирдания Хузяхметовна — Көмеш-Күл авыл жирлеге секретаре.

Комиссия әгъзалары

3.Кашапова Дания Тагировна — Көмеш-Күл авыл җирлегенең 7нче санлы округ буенча депутаты

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Кулавыл җирлеге
Башкарма комитетының
05 март 2021 ел.№6
карарына
3 нче кушымта

Авария хәлендәге, коры-сары һәм куркыныч тудыручы
яшел утыртмаларны кисү буенча комиссия турындагы Нигезләмә

1. Авария хәлендәге, коры-сары һәм куркыныч тудыручы яшел утыртмаларны кисү буенча комиссия турындагы әлеге Нигезләмә «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның .10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән һәм авыл җирлеге территориясендә авария хәлендәге, коры-сары һәм куркыныч тудыручы яшел утыртмаларны агач һәм куакларны кисүнең һәм (яки) күчереп утыртуның максатчанлыгын бәяләү комиссиясе эшчәнлеге тәртибен билгели.

Комиссиянең бурычлары булып тора:

1) авыл җирлеге милкендәге һәм (яки) авыл җирлеге территориясендәге дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрендә агач һәм куакларны законсыз кисүне һәм (яки) күчереп утыртуны кисәтү;

2) агач һәм куакларны кисү һәм (яки) күчереп утырту сәбәпләрен үз вакытында, һәрьяклы, тулы һәм объектив карау;

3) кисү һәм (яки) күчереп утырту планлаштырыла торган агачлар һәм куаклар урнашкан территорияне тикшерү актын төзү;

4) агач һәм куакларны кисүгә һәм (яки) күчереп утыртуга рөхсәт бирү яисә нигезле итеп кире кагу;

5) чыгарылган карарларның үтәлешен контрольдә тоту.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнарга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия хокуклы:

1) җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын комиссия утырышларында тыңларга;

2) Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча карарлар әзерләүдә катнашу өчен федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары белгечләрен җәлеп итәргә. ;

7. Комиссия авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән төзелә, үзгәртеп корыла һәм бетерелә.

8. Комиссия җитәкчесе булып вазифасы буенча авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе дә тора.

9. Комиссия Җитәкчесе:

1) Комиссия эше белән җитәкчелек итә;

2) комиссия утырышларында рәислек итә;

4) комиссия эшенең сыйфаты, кабул ителә торган карарларның объективлыгы, аның эш нәтиҗәләре буенча документларны үз вакытында рәсмиләштерүнең үз вакытында башкарылуы өчен җавап бирә.

Комиссия секретаре:

1) календарь елда комиссия утырышларын уздыру графигын эшли;

2) эшче төркем утырышын үткәрү вакыты һәм урыны турында комиссия әгъзаларына хәбәр итә;

3) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара һәм рәсмиләштерә.

Комиссия әгъзалары:

1) комиссия эшендә катнашалар;

2) карала торган мәсьәлә буенча үз фикерләрен белдерәләр (аерым фикер булганда-язма рәвештә);

3) кабул ителә торган карарларның объективлыгы һәм компетентлыгы өчен җавап бирәләр;

4) утырышны үткәрү датасына кадәр кимендә ике көн алдан эшче төркем утырышында булу мөмкинлеге булмаган очракта, комиссия секретарен кисәтәләр.

10. Комиссия үзенең компетенциясенә караган мәсьәләләрне коллегиаль рәвештә карый һәм хәл итә.

11. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

12. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, тавышлар саны тигез булса, Рәис тавышы хәлиткеч булып тора, беркетмә төзелә, аңа рәислек итүче һәм комиссия секретаре тарафыннан комиссия утырышы узган көнне имза салына.

13. Комиссия үз эшчәнлеген комиссия утырышында кабул ителә һәм аның җитәкчесе тарафыннан раслана торган эш планы нигезендә башкара.

14. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.